**Республика Татарстан**
**СОВЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№17 02.10.2017 ел

"Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында"

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2003 елның 6 октябрендәге 13-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 ст. 21, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 13-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п. 1, Мортыштамак авыл җирлеге Уставының 11 ст. карары нигезендә «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 сентябрендәге 16-09 номерлы карары нигезендә Мортыштамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2017 елның 19 ноябренә Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

“2018 елда үзара салым чараларын Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 250 сум күләмендә кертүгә, I төркем инвалидлардан һәм ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Бөек Ватан сугышы катнашучыларыннан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?”

1) ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән:

- мәдәни чаралар үткәрүнең музыкаль аппаратурасын сатып алу;

- мәдәни чаралар өчен бүләкләр сатып алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны да кертеп), шул исәптән:

- Колмәт авылы балалар мәйданчыгын сатып алу;
- Мортыштамак авылы һәм Колмәт авылы өчен яктылык диодлы лампочкалар сатып алу һәм урнаштыру;

махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәте өчен түләү);

- җирлекнең торак пунктларында көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю урыннарын чистарту;

3) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту, шул исәптән:

- зират коймалары өчен төзелеш материаллары сатып алу

Мортыштамак авылында.

4) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, шул исәптән:

- Мортыштамак авылы яр буе урамында вак таш ташу, вак таш җәю.

әйе юк

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Мортыштамак авыл җирлеге

Совет Рәисе: Әхмәтгәраев М.Н